**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**28 .12. 2023** **№ 42-2**

**2023 елда Тәтеш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәү һәм 2024-2026 елларга фаразы турында**

Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Д. Храменкованың 2023 елда Тәтеш муниципаль районының социаль-икътисади үсеш фаразын үтәү һәм 2024-2026 елларга фаразлау турындагы мәгълүматларын тыңлап һәм фикер алышып, Тәтеш муниципаль районы Советы 2023 елда тулаем районда тотрыклы социаль-икътисади хәл булуын билгеләп үтә. 2023 елда фаразланган күрсәткечләрне үтәү икътисадның реаль секторын үстерүне, 2024-2026 елларга Тәтеш муниципаль районын үстерүнең тиешле юнәлешләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итәчәк.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Тәтеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Д. Храменкованың 2023 елда Тәтеш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше фаразын үтәү һәм 2024-2026 елларга фараз турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Тәтеш муниципаль районының 2024-2026 елларга социаль-икътисади үсеш фаразлары күрсәткечләрен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

3. Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә органнары, предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә барлык төр ресурсларны экономияләү режимын үтәп, фараз күрсәткечләрен үтәү буенча тулы чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

4. Тәтеш муниципаль районы эш бирүчеләренә хезмәткәрләрнең тулы булмаган мәшгульлек режимын кулланмаска һәм хезмәт хакын закон нигезендә билгеләнгән минималь дәрәҗәдән түбәнрәк түләргә рөхсәт итмәскә киңәш итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Советының бюджет, икътисад һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**